# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы  Зирекле  авыл җирлеге составына керүче Зирекле авылы

13 ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районыңц Зирекле авыл җирлеге составына керүче  Зирекле торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда  Зирекле  авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы  студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге  чараларга юнәлдерергә:

- Җирлек эчендәге юлларны караптоту;

- Торак пунктларда урамнарны яктырту.

- Контейнер мәйдан чыкларытөзү

3.Әлеге карарны Зирекле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга Зирекле авылы.Ун як яр урамы  35 йорт

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зирекле авыл җирлеге башлыгы В.А.Данилова